Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение гимназия с. Раевский

| СОГЛАСОВАНО | РАССМОТРЕНО | УТВЕРЖДАЮ |
|---|---|---|
| на заседании ШМО учителей башкирского языка и татарского языка<br>Протокол №1<br>от «26» августа 2016г. | на заседании научно - методического совета<br>Протокол №1<br>от «29» августа 2016г. | Директор МБОУ гимназия с. Раевский<br>_________________Колеганов С. Н.<br>Приказ №<br>от «29» августа 2016г. |

# Рабочая программа

## по родному языку

## в 8б классе

Срок реализации: 2016-2017 учебный год

Составитель: учитель татарского языка и литературы Насырова Л.М.

Составлено на основе программы по татарскому языку и литературе («Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары»,Казан, «Мәгариф», 2010 )

2016 год

# ЭЧТӘЛЕК

I. Аңлатма язуы.
II. Укыту предметына гомуми аңлатма.
III. Укыту предметының укыту планында тоткан урыны.
IV. Укытуның гомуми, шәхси, метапредмет нәтиҗәләре.
V. Укыту предметының төп эчтәлеге
VI. Укыту предметының сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча планлаштырылган нәтиҗәләре.
VII. Укыту предметының темаларга якынча бүленеше.
VIII. Укытуны материаль-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү.

МБОУ гимназия с.Раевский. Насырова Л. М.

# Аңлатма язуы

Эш программасы статусы

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:

1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы (“Закон об образовании” Закон Российской Федерации)
2. “Мәгариф турында” Башкортостан Республикасы Законы.
3. Гомуми белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумы
4. ”Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010нчы ел.
5. Раевка авылы гимназиясенең 2015-2016 нчы уку елына расланган укыту планы
6. Дәреслек: Р.Ә. Асылгәрәева, М.З. Зиннәтовна ”Татар теле” 7 нче сыйныф, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010нчы ел.

Соңгы елларда республикада татар теленең куллану даирәсе киңәйде, иҗтимагый функциясе көчәйде. Милләтара мөнәсәбәтләрне якынлаштыручы, җайга салучы чара буларак та аның мөмкинлекләре үсте. Укучыларда лингвистик(тел), аралашу(коммуникатив), этнокультура өлкәсенә караган (культурологик) компетенцияләр булдыру рус мәктәбендә татар теленә өйрәтүнең максатын тәшкил итә.

Лингвистик компетенция (укучыларның ана телелннән мәгълүматлылыгы) фонемалар, морфемалар, сүз ясалышы, сүзтезмәләр, җөмләләр, җөмлә кисәкләре, лексик һәм грамматик берәмлекләр, лингвистик анализны һ.б. үз эченә ала.

Аралашу (коммуникатив) компетенциясе ул – башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы; хәзерге татар теле нормаларына ия булу, сүз байлыгын, сөйләмнең грамматик ягын дөрес итеп үзләштерү; телдән һәм язма формада бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен булдыру һ.б.

Этнокультура өлкәсенә караган (культурологик) компетенция, ягъни телне милли-мәдәни яссылыкта үзләштерү ул – укучыларны сөйләмгә милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен белү, татар сөйләм этикетына ия булу.

Эш программасы тел һәм әдәбият темаларын берләштерелеп төзелде, чөнки дәрес 2015-2016 нчы уку елына расланган укыту планында “Туган тел” буларак бирелә.

МБОУ гимназия с.Раевский. Насырова Л. М.

# Укыту предметына гомуми аңлатма

Татар теле һәм әдәбиятын укыту максатлары

## Танып белү максатының эчтәлеге

Башкортостан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналгантатархалкымәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихиүткәнен, бүгенгесен, киләчәгенбелүзарур. Татархалкыбеләнкулга-култотыныпяшәргәәзерләнүчеһәркешебухалыкның бәйрәмнәрен, традицияләренаңларга, хөрмәтитәргә, әдәбият-сәнгатьвәкилләренең иҗадиказанышларыбеләнүзенең рухиүсешенбаетаалумөмкинлегеннәнфайдаланыргатиеш. Программаэчтәлегетелгәөйрәтүпроцессынбалаөчен “башкадөньягатәрәзәачу” булырлыкһәмшуның аркылыаның үзяшәешендәтулыракаңлавынаярдәмитәрлекитепсайланды.

Урта баскычта татар халкының рухи дөньясын чагылдырган, тормыш – көнкүрештәге әхләкый проблемаларны үз эченә алган, укучыларның кызыксынуларына, яшь үзенчәлекләренә туры килгән әдәби әсәрләрбелән танышу;Татарстандаяшәүчемилләтләр, Татарстанның дәүләтсимволлары, Татарстанның территориясе, географикурыны;башкалабызКазанның тарихи үткәне, бүгенгейөзе;татарсәнгатенең төрлетармакларыбуенчакүренеклешәхесләр турында укучыларның татарчасөйлиалуларытөпмаксатитепкуела.

Югары баскычта укучылар 1-9 сыйныфларда алган белемнәрен тагын да тулыландыралар, киңәйтәләр, гомумиләштерәләр. Урта баскычта өйрәнелгән темаларга өстәп, укучыларны Башкортостанның сәнәгый-икътисади, фәнни һәм мәдәни үсеш дәрәҗәсе, халыкара элемтәләре, Россиядә һәм дөнъяда тоткан урыны, яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләр һәм спорт казанышлары турында иркен аралашуга чыгару максат итеп куела.

## Үстерү максатының эчтәлеге

Шәхеснең белемлебулуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләүсәләтеүсешедәрәҗәсеннән дәтора. Укытупроцессындаүстерү, тәрбиямаксатларындаимикүзаллапэшләү –укытуның практикягыуңышлылыгының алшарты. Балаларның психикүсешентүбәндәгеюнәлешләрдәүстерүгәаеручаигътибарбирүталәпителә:

– фикерләүнеүстерүбеләнбәйлепсихикфункцияләр: логикфикерләү, сәбәп-нәтиҗәбәйләнешләрентабу, индуктив, дедуктивфикерләү;

– хәтернеүстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкныүстерү;

– аралашабелүсәләтенүстерү (аралашучанлык, хисләлек, эмпатияхисләре);

– ихтыяр көче, максатчанлык, активлыккебексәләтләрнеүстерү.

Программагасайланганэчтәлекнигезендәсөйләмэшчәнлегенең барлыктөрләребуенчадаэшоештырганда,бумаксатларберенчеплангакуела.

## Тәрбияви максатның эчтәлеге

Укучыларның тиешледәрәҗәдәгетәрбиялелегеннәнбашкаукытупроцессыноештырумөмкинтүгел. Тәрбияпроцессы, беренчеиратта, укытуның эчтәлегеһәмметодларыбеләнбәйле. Шуңакүрәпрограммаэчтәлегенсайлаганда, материалның тәрбиявимөмкинлекләренисәпкәалу мөһим.Эчтәлектәәхлакыйпроблемаларбулгантекстларүзләреүккоммуникативмотивациягәия, шунлыктанаралашуситуациясебулдыруәлләникыенлыктудырмый. Башкамилләтвәкилләренең күңеленяулардай,

алардагомумкешелекəхлакыйсыйфатларнытəрбиялəрдəйтатарəдəбиятыөлгелəребелəнтаныштырудашушыукмаксаткабуйсындырыла,сөйлəшү -аралашугаалыпчыгугакулайракбулганəдəбиəсəрлəртəкъдимителə.

Белем бирү максатының эчтəлеге

Укучыларның татартелебуенчалексик, грамматиккүнекмəлəрефилологикбелемнəрсуммасыдəрəҗəсендəгенəкалмыйча, əсөйлəмэшчəнлегенең барлыктөрлəрендəдəаралашудакулланырлыкдəрəҗəгəҗитүезарур. Ягъни, укучылар, ниндидəбулсасүзне, яграмматиккатегориянетану, аеру, аңлау, тəрҗемəитүдəрəҗəсендəгенəтүгел, аларныаралашумаксатыннанмөстəкыйлькулланырлыкдəрəҗəдəөйрəнергəтиешлəр.
Шулвакыттагынататартелендəүлəттелебуларакөйрəнүбурычыүтəлə.

Белем бирү эчтəлегенең мəҗбүри минимумы

Коммуникатив компетенция. Сөйлəм. Телдəн һəм язма сөйлəм. Диалогик һəм монологик сөйлəм. Сөйлəм стильлəре. Матур əдəбият теле.

Телдəн һəм язма сөйлəмне аеру. Тел берəмлеклəрен аралашуны ситуация үзенчəлеклəренə карап сайлый белү. Аралашу өлкəсенə һəм ситуациясенə бəйле рəвештə телдəн һəм язма сөйлəмне дөрес файдалану.

Текстның темасы, төп фикере һəм төзелеше. Аларның стильлəрендə жанр төрлелеге.

Татар əдəби теле һəм аның нормалары турында төшенчə.

Сөйлəм эшчəнлеге төрлəрен (тыңлап аңлау, сөйлəү, уку һəм язу) үзлəштерү.

Укуның төрле төрлəрен (танышу, өйрəнү һ.б.)үзлəштерү. Уку киталары, масса күлəм мəгълүмат чаралары, интернет һ.б. чаралар белəн эшлəү алымнарын үзлəштерү.

Иҗтимагый-мəдəнии, əхлакый, көнкүреш, уку темаларына бəйле булган монологтк һəм диалогик сөйлəм үрнəклəрен төзү.

Текстның эчтəлеген кыскача , тулы яки сайлап алып сөйлəү. Диктантлар, изложениелəр һəм сочинениелəр язу. Төрле стилҗ һəм жанрдагы текстлар төзү: бəялəмə, аннотация, хат, ышаныч кəгазе, гариза, тезис, конспект һ.б.ш.

Лингвистик компетенция. Телнең кеше тормышында һəм җəмгыятьтə тоткан урыны. Татар теле – Татарстан Республикасының дəүлəт теле. Татар теле – татар халкының милли теле.

Матур əдəбият һəм аның нормалары турында төшенчə.

Татар теленең үсештə булуы. Соңгы елларда татар теле лексикасындагы үзгəрешлəр.

Тел белеменə караган сүзлеклəр һəм алардан файдалану.

## Укыту предметының укыту планында тоткан урыны

Укыту планында 8 нче сыйныфта татар теленнән (туган тел) атнага 2 сәгать вакыт бирелә. Барлыгы 68 сәгать.

МБОУ гимназия с.Раевский. Насырова Л. М.

# Укытуның гомуми, шәхси, метапредмет нәтиҗәләре

Төп һәм (урта)гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәнияткә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Төп һәм урта (тулы) гомуми белем бирү баскычларында татар теленә өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә гомуми нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– укучыларныңкоммуникатив компетенциясен(аралашу осталыгын) үстерү, ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашукүнекмәләре булдыру;

– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә арашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;

– “Татар теле һәм әдәбияты” фәненәкарата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыруһәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

## Укытуның шәхси нәтиҗәләре

Төп һәм урта (тулы) гомуми белем бирү баскычларын төгәлләгәндә,укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана:

– шәхесара һәм мәдәниятара аралашудататар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;

– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;

– әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;

– “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”,төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.

## Укытуның метапредмет нәтиҗәләре

Төп һәм(урта) белем бирү баскычларындататар теле һәм әдәбиятын укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (*танып-белү, регулятив, коммуникатив)*формалаштыругахезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрән*ә; у*кучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алукүнекмәләре формалаша.

*Танып-белүнәтиҗәләре:*

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;

– иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;

– объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;

– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
– тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

*Регулятив нәтиҗәләр*:

– уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
– уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
– билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
– укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
– ихтыяр көче,максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
– дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
– дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

*Коммуникатив* нәтиҗәләр:

– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
– әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
– парларда һәм күмәк эшли белү;
– мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
– әңгәмәдәшең белән контактны башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

# Укыту предметының төп эчтәлеге

*Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:*

- ана теленең төп берәмлекләрен һәм аларның билгеләрен белү;
- телдән һәм язма сыйләм, диалог, монолог, аралашу ситуацияләрендә тел стильләре, текст төшенчәләрен аңлау һәм гамәлдә дөрес куллану;
- тыңлап аңлау һәм уку буенча телдән һәм язма рәвештә (радио, телеведениедән һ.б.) хәбәр ителгән мәгълүматны аңлау;
- сөйләү һәм язуда татар әдәби теленең төп нормаларын (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик һәм пунктацион)саклау һәм сөйләм әхлагы нормаларын үтәү;
- татар теленең фонетик, лексик системаларын һәм грамматик төзелешен үзләштерү;
- сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерә белү;
- ана теленең грамматик категорияләрен белү;
- грамматик үзенчәлекләренә карап, сүз төркемнәрен аера белү;
- сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау;
- сүз, сүзтезмә, җөмләләрдәге хаталарны төзәтү;
- җөмләгә синтаксик анализ ясау;
- төрле сүзлекләрдән һәм белешмә характерындагы китаплардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан урынлы файдалану;
- текстның эчтәлеген телдән яки язмача төгәл итеп, сайлап яки кыскача, гади һәм кушма җөмләләр кулланып сөйли белү;
- бирелгән темага, куелган максатка ярашлы рәвештә, төрле ситуацияләрдән чыгып, сурәтләү яки хикәяләү характерындагы текстларны телдән яки язмача әзерлзү;
- сорауларга тулы һәм дөрес итеп җавап бирү;
- төрмыш-көнкүреш, уку, иҗтимагый, мәдәни темаларга әңгәмә кору, үз фикереңне яклап, әңгәмә-бәхәс формасында сөйләшү күнекмәләренә ия булу
- текстның планын төзү ;
- тәкъдим ителгән текстларны рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү;
- ана теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау;
- татар теле дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрне ана теленең кеше һәм җәмгыять тормышында алып торган урынын аңлап куллана һәм бәяли белергә өйрәнү, татар теленең Татарстан Республиуасында дәүләт теле буларак өйрәнелүен, аның иҗтимагый әһәмиятенең артуын аңлау

VI нчы сыйныфта татар теленнән үзләштерелергә һәм камилләштерелергә тиешле гомумкүнекмәләр

| Уку эшчәнлеген оештыра белү юнәлешендә | Китап, өстәмә мәгълүмат белән эш итү | Фикерләү белән бәйле күнекмәләр | Телдән һәм язма сөйләм үстерү һәм аралаша белү юнәлеше |
|---|---|---|---|
| 1. Уку мәсьәләләрен мөстәкыйль билгеләү<br>2. Уку операцияләрен планлаштыру.<br>3. Белем алуның рациональ ысулларын сайлау.<br>4Үзеңнең уку һәм танып-белү эшчәнлегеңне анализлау, аңа бәя бирү.<br>5.Мөстәкыйль белем алу буенча эш башлау. | 1. Дәреслек белән эш итә белү.<br>2. Төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эш итә белү.<br>3. Төрле текстлар белән эш иткәндә сәнгатьлелекне саклый белү.<br>4. Эчтәлекне аңлап, тиешле тизлектә, дөрес уку:<br>-уку елы башында -75-85 сүз<br>-уку елы ахырында-85-95 сүз<br>5. Сүзлекләрдән файдалана белү, белешмә әдәбият белән система лы эшләү.<br>6. Вакытлы матбугат басмалары һәм аудио- видео белән даими эшли белү. | 1.Уку мәсьәләсен куя белү.<br>2. Яңа теманы аңлауга мотив тудыру.<br>3. Танып белү активлыгын үстерү.<br>4. Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү күнекмәләрен камилләштерү.<br>5. Грамматик анализ төрләрен үзләштерү:<br>- мөстәкыйль сүз төркемнәренә морфологик анализ;<br>- ярдәмлек сүз төркемнәренә морфологик анализ;<br>-гади җөмләгә синтаксик анализ;<br>6. Тикшеренү ысуллары:<br>- модельләштерү;<br>-охшатып эшләү.<br>7. Логик алымнардан чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау күнекмәләре булдыру. | 1. Телдән сөйләм:<br>-Кагыйдәләрне аңлап эзлекле сөйли белү күнекмәсе;<br>- Сорауны формалаштыра белү һәм тулы җавап бирә белү күнекмәсе;<br>- Диалоглар төзү күнекмәсе;<br>2. Язма сөйләм:<br>-күчереп язу;<br>-фикер йөртү элементлары кертеп, әзер план буенча бирелгән темага сочинение язу- 6 (1)<br>-катлаулы план буенча изложение язу- 5 (2)<br>уку елы башында 140-160 сүзле текст (язма күләме 85-95 сүз) уку елы ахырында 160-190 сүзле текст (язма күләме955-105 сүз);<br>-сүзлек диктанты – 18-25 сүз<br>-контроль диктант- 55-65 сүз;<br>-эш кәгазьләре язу ( акт, расписка.) |

| № | Төп темалар | Сәг. | Белем һәм күнекмәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 5сыйныфта үткәннәрне кабатлау. | 1 | - аваз-хәреф анализы,сүз ясалышы, сүз төзелеше, ; |
| 2 | Сүз төркемнәре | 1 | - морфология- тел белеменең сүз төркемнәрен өйрәнә торган бүлеге |
| 3 | Исем | 5 | - ялгызлык, уртаклык исемнәр, исемнәрнең ясалышы,морфологик анализ ясау; |
| 4 | Сыйфат | 5 | - сыйфат төркемчәләре,асыл һәм нисби сыйфатларны бер-берсеннән аера белү, аларның исемләшеүе, төле ысуллар белән ясалышы,морфологик анализ ясау; |
| 5 | Сан | 5 | - саннарның саналмыш белән куллану үзенчәлеге, татвар телендә аларның исемләшүе, сан төркемчәләре, аларның ясалышы һәм дөрес язылышы, морфологик анализ ясау; |
| 6 | Рәвеш | 2 | - рәвеш төркемчәләрен, ясалыш үзенчәлекләрен, морфологик анализ ясау; |
| 7 | Алмашлык | 6 | - алмашлык төркемчәләре, аларның сөйләмдәгеәһәмияте, морфологик анализ ясау; |
| 6 | Әдәби әсәрләр өйрәнү | 7 | |

# Укыту предметының темаларга якынча бүленеше

| № | Сәгать саны | Бүлекләр һәм темалар | Үзләштерелергә яки камилләште-релергә тиешле белем һәм күнекмәләр | Контроль төре | Өй эше | | Үткәрү вакыты | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 5-7 СЫЙНЫФЛАРДА ҮТКӘННӘРНЕ КАБАТЛАУ | | | | | | |
| 2 | 1 | Үткәннәрне кабатлау | Ясалышлары ягыннан сүзләрнең тамыр һәм ясалма сүзләргә бүленүен, кушымчаларның сүз ясагыч, мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларга бүленүен искә төшерү. Сүзләрне мәгънәле кисәкләргә таркату Сүз төркемнәре турында гомуми төшенчәне искә төшерү. Сүз төркемнәренең морфологик һәм синтаксик билгеләрен искә төшерү<br><br>Фигыль төркемчәләрен искә төшерү<br><br>Татар һәм рус телләрендә җөмләдә сүзләр тәртибен искә төшерү | Тестлар куллану Бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзеп язу. | ”Көзге таби-гать”шигырь яки хикәя. | 05.09. | | |
| | | | | | | | | |
| | | ҖӨМЛӘДӘ СҮЗЛӘР БӘЙЛӘНЕШЕ | | | | | | |
| 2 | 2 | Җөмләдә сүзләр бәйләнеш | Җөмләдә сүзләрнең түбәндә саналган грамматик чаралар ярдәмендә бәйләнүе: килеш кушымчалары, бәйлек яки бәйлек сүз, теркәгеч һәм | Тәрҗемә итү | Кагыйдәне укырга. | 19.09 | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | санау интонациясе яки бары тик санау интонациясе, сүзләрнең урнашу тәртибе, ия белән хәбәрнең бер үк зат-сан формасында килүе. Нинди грамматик чара ярдәмендә формалашудан чыгып, җөмләдә сүзләр бәйләнешенең икегә: тезүле һәм иярүле бәйләнешләргә бүленүе. | | . | | | |
| | | | | | | | | |
| 3 | 1 | Сүзтезмә | Кимендә ике мөстәкыйль сүзнең үзара бәйләнешкә керү нәтиҗәсендә сүзтезмә барлыка килүе. Сүзтезмәнең аерым бер төшенчәгә конкретлык, төгәллек бирүе. Сүзтезмәнең иярүче һәм ияртүче кисәкләрдән торуы. Ияртүчедән чыгып, иярүче кисәккә сорау кую. Ияртүче кисәкнең кайсы сүз төркеменнән булуына карап, сүзтезмәләрне 6 төркемгә: исем сүзтезмә, сыйфат сүзтезмә, сан сүзтезмә, алмашлык сүзтезмә, фигыль сүзтезмә, рәвеш сүзтезмәгә бүленүе. | 10 мин контроль эш: сүзтезмәләр-не тикшерү | 52 нче күнегү, 10 сүзтезмә аерып алып тикшерергә. | 26.09. | | |
| | | И К Е   С О С Т А В Л Ы   Җ Ө М Л Ә Л Ә Р | | | | | | |
| 4 | 1 | Ия һәм аның белдерелүе. | Баш килештә килеп, җөмләдә башка сүзләргә | | 1.Кагыйдәне укырга | 03.10. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | буйсынмыйча, кем? нәрсә? яки ни? сорауларына җавап бирә торган кисәкнең ия дип аталуы. Җөмләдә баш килештә килгән исем яки алмашлыкның ия булуы. Сыйфат, исем фигыль, сан һәм алмашлыкларның да исем мәгънәсендә килгәндә ия була алулары. Иянең тезмә сүз белән дә белдерелүе. | | 2.а) 65 нче күнегү, бирем буенча;<br>б) бер мәкаль нең мәгънәсен аңлатып яз | | | |
| 5 | 1 | Хәбәр һәм аның белдерелүе. | Ия турында ни дә булса хәбәр итә торган җөмләнең баш кисәгенең хәбәр дип аталуы. Хәбәрнең нишли? нишләде? нишләр? нишләгән? ул кем? ул нәрсә? ул нинди? ул ничек? ул кайдан? ул ничә? кебек сорауларга җавап булуы. | Тәрҗемә итү | 1.Кагыйдән е укырга<br>2.75 нче күнегү бирем буенча<br>3. 76 нчы күнегү, бирем буенча. | 10.10. | | |
| 6 | 1 | Ия белән хәбәр арасында сызык | Җөмләнең хәбәре баш килештәге исем яки исем урынына килгән башка сүз төркеме белән белдерелгәндә, ия белән хәбәр арасына сызык куелуы. | Тәрҗемә итү | 82 нче күнегүбирем буенча | 17.10. | | |
| 7 | 1 | Кабатлау. Ия һәм хәбәр | Ия белән хәбәр турында белемнәрне ныгыту | Контроль тест | 84 нче күнегү, бирем буенча. | 24.10 | | |
| | | ҖӨМЛӘНЕҢ ИЯРЧЕН КИСӘКЛӘРЕ | | | | | | |
| 8 | 2 | Җөмләнең иярчен | Баш кисәкне ачыклап, аңа | | 95 нче | 31.10. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кисәкләре. Аергыч һәм аның белдерелүе. | ияреп килә торган кисәкнең иярчен кисәк дип аталуы. Иярчен кисәкләр: аергыч, тәмамлык, хәл, аныклагычлар. Аларга баш кисәкләрнең берсеннән чыгып сорау бирелү. Җөмләдә исем белән белдерелгән кисәкне ачыклап килүче нинди? кайсы? кемнең? нәрсәне? ничә? ничәнче? сорауларының берсенә җавап булган кисәкнең аергыч дип аталуы. Аергыч ачыклап килгән сүзнең аерылмыш булуы. | | күнегү, бирем буенча. | | | |
| | | | | | | | | |
| 9 | 1 | Тәмамлык һәм аның белдерлүе | Җөмләнең фигыль белән белдерелгән кисәген ачыклап, кемгә? нәрсәгә? кемнән? нәрсәдән? кемдә? нәрсәдә? кем белән? нәрсә белән? нем тарафыннан? нәрсә тарафыннан? ничәне? ничәдән? кебек сорауларының берсенә җавап булган кисәкнең тәмамлык дип аталуы. Тәмамлыкның исем һәм исем мәгънәсендә килгән башка сүз төркеме белән белдерелүе. Тәмамлыкның үзен ияртkән сүзгә төрле килеш кушымчалары, бәйлек һәм бәйлек сүзләр | | Сочинение: “Яраткан шөгылем” | 07.11. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ярдәмендә бәйләнүе. | | | | | |
| 10 | 1 | Туры һәм кыек тәмәмлыклар | Җөмләдә төшем килешендәге исем һәм исем мәгънәсендә килгән башка сүз төркеме белән белдерелгән тәмамлыкның туры тәмамлык дип аталуы. Иялтүче сүзгә юнәлеш, чыгыш һәм урын-вакыт килеше кушымчалары яки бәйлек (бәйлек сүз) белән бәйләнгән тәмамлыкларның кыект тәмамлыклар дип аталулары. | 5-7 мин тест | 117 нче күнегү, сөйләшүгә әзер- ләнеп килергә.<br>2. 116 нчы күнегү. Хат язу. | 14.11. | | |
| 11 | 1 | Бсү. Изложение (контроль) | Эчтәлекне аңлау, гади план нигезендә төгәл итеп язып бирү | Изложение №2 “Туган мәктә- бем”. 216 нчы бит | | 21.11. | | . З.Н. Хәбибуллина, М.А. Вәлиуллин, Х.Г. Фәрдиева.<br>V-XI сыйныфлар өчен язма эшләр, Казан, 2003. |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12 | 1 | Хәл һәм аның төрләре. Урын хәле Вакыт хәле | Җөмләдә эш яки хәлнең кайда? ничек? кайчан? нинди шартларда үтәлүен яки үтәлмәвен белдерә торган иярчен кисәкнең хәл дип аталуы. Хәлләрнең күбрәк фигыль белән белдерелгән җөмлә кисәген ачыклап килүе. Җөмләдә эш яки хәлнең урынын белдереп, кайда? кая? кайда? сорауларының берсенә җавап бирә торган хәлнең урын хәле булуы. Җөмләдә эш яки хәлнең вакытын белдереп, кайчан? кайчанга чаклы? кайчаннан бирле? сорауларының берсенә җавап бирә торган хәлнең вакыт хәле булуы. | | 125 нче күне- гүдәге шигырь не ятларга, хәтер диктанты итеп язарга әзерләнергә. | 28.11. | | |
| 13 | 1 | Рәвеш хәле Күләм хәле | Җөмләдә эш яки хәлнең рәвешен белдереп, ничек? ни рәвешле? сорауларының берсенә җавап бирә торган хәлнең рәвеш хәле булуы. | | 132 нче күнегү, бирем буенча. | 05.12. | | |
| 14 | 1 | Сәбәп хәле Максат хәле | Җөмләдә эш яки хәлнең, сәбәбен белдереп, ни сәбәпле? ник? нигә? ни (нәрсә) аркасында? ни өчен? кебек сорауларының берсенә җавап бирә торган хәлнең сәбәп хәле булуы. | | 145 нче күне- гүдәге шигырьне ятларга, хәтер диктанты итеп язарга әзерләнергә | 12.12. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | 1 | Контроль диктант | | Диктант №3 “Олылар сүзе” | | 19.12. | | З.Н. Хәбибуллина, М.А. Вәлиуллин, Х.Г. Фәрдиева. V-XI сыйныфлар өчен язма эшләр, Казан, 2003, 56 нчы бит |
| 16 | 1 | Шарт хәле<br>Кире хәл | Җөмләдә эш яки хәлнең шартын белдереп, нишләсә? нинди шартта? сорауларының берсенә җавап бирә торган хәлнең шарт хәле булуы.<br>Җөмләдә көтелгән эш яки хәлнең киресе булачагын белдереп, нишләсә дә? нәрсәгә карамастан? сорауларының берсенә җавап бирә торган хәлнең кире хәл булуы. | | 157 нче күнегү, бирем буенча. | 26.12. | | |
| 17 | 1 | Сочинение | “Туган ягым” | | | 16.01. | | |
| 18 | 1 | Аерымланган хәлләр һәм алар янында тыныш билгеләре | Аерым бер мәгънәгә ирешү өчен, интонацион яктан бүленеп әйтелгән иярчен кисәкләрнең аерымланган иярчен кисәкләр дип аталуы.<br>Үзләре буйсынган җөмлә кисәгеннән ераклашкан һәм аерым хәбәрлек төшенчәсенә ия булган хәлләрнең аерымлануы.<br>Аерымланган хәлләрнең башка җөмлә кисәкләреннән өтер яки | | 163 нче күнегү, бирем буенча | 23.01. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | өтерләр белән аерып алынуы. Уртада килгәндә, аерымланган хәлләрнең ике яктан да өтер белән аерылуы, калган очракта өтернең бер яктан гына куелуы. | | | | | |
| 19 | 1 | Төрле хәлләрнең аерымлануы | Үзләре бәйләнгән җөмлә кисәгеннән ераклаштырылган һәм ярым хәбәрлек төшенчәсенә ия булган вакыт, рәвеш, сәбәп, максат, шарт һәм кире шарт хәлләренең аерымлануы. Аерымланган хәлләрнең җөмләдә төрле урында килүләре. | | 175 нче күнегү, бирем буенча. 177 нче күнегү, бирем буенча | 30.01. | | |
| 20 | 1 | Хәлләрне кабатлау | Хәлләрне кабатлау | Тест, тәрҗемә күнегүләре | 185 нче күнегү, бирем буенча | 06.02. | | |
| | | ЖӨМЛӘНЕҢ МОДАЛЬ КИСӘКЛӘРЕ | | | | | | |
| 21 | 1 | Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре. | Сөйләм төбәп әйтелгән затны яки предметны белдерә торган сүз яки сүзләр тезмәсенең эндәш сүз дип аталуы. Кешедән кала башка предметларга төбәп эндәшү сынландыру (сурәтләү чарасы) дип аталуы. Эндәш сүзләрнең баш килештәге зат яки сынландырылган предмет исемнәре белән белдерелүе; җыйнак та, җәенке дә була | | 205 нче күнегү, бирем буенча Шигырьне хә- тер диктанты итеп язарга әзерләнеп килергә. | 13.02. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | алулары. Зат алмашлыкларының бер вакытта да эндәш сүз була алмаулары. Эндәш сүзләрнең җөмләнең гомуми интонациясеннән аерымрак әйтелүләре. Эндәш сүзләр янында өтер, өндәү билгеләре куелу. Бер гомуми интонация астында әйтелгән *и, ай, әй, о* ымлыклары белән эндәш сүзләр арасында өтер куелмауы. | | | | | |
| 22 | 1 | Кереш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре. | Сөйләүченең җөмләдәге уйга булган мөнәсәбәтен (ышану һәм раслауны; шикләнү, икеләнү яки чама белән әйтүне; үтенү яки үз фикереннән чигенүне; фикер чыганагын, фикер нәтиҗәсен яки йомгагын, яисә аның алдагы фикергә бәйләнешен; фикер тәртибен, фикергә бәйле тойгыларны) белдерә торган сүзләрнең кереш сүзләр дип аталуы. Кереш сүзләрнең җыйнак та, җәенке дә була алулары. Кереш сүзләрнең җөмләнең башка кисәкләреннән өтер белән аерылулары. | | 214 нче күнегү, бирем буенча | 20.02. | | |
| 23 | 1 | Сочинение “Кем булырга, нинди | | сочинение | | 27.02. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | булырга?” | | | | | | |
| | | Ж Ө М Л Ә Н Е Ң  Т И Ң Д Ә Ш  К И С Ә К Л Ә Р | | | | | | |
| 24 | 1 | Тиңдәш кисәкләр. Тиңдәш кисәкләр янында бәйләүче чаралар. | Җөмләдә бер үк сүзгә (җөмлә кисәгенә) караган һәм бер үк сорауга җавап булган кисәкләрнең тиңдәш кисәкләр дип аталуы. Тиңдәш кисәкләрнең *тезүче теркәгечләр (җыючы, каршы куючы, бүлүче теркәгечләр)* белән дә теркәгечләр булмыйча, тик *санау интонациясе* ярдәмендә дә үзара бәйләнүе. | | 225 нче күнегү, бирем буенча 227нче күнегү, бирем буенча | 06.03. | | |
| 25 | 1 | Тиндәш кисәкләр янында тыныш билгеләре. | Теркәгечләрдән башка гына бәйләнгән тиңдәш кисәкләр арасына өтер, нокталы өтер, сызык куелу очраклары. Тиңдәш кисәкләр янында *һәм, яки* теркәгечләре кабатланмаса, өтернең куелмавы. Исемне төрле яктан ачыклап килгән аергычларның тиңдәш түгел аергычлар дип йөртелүе, алар арасына өтер куелмавы. | | 234 нче күнегү, бирем буенча Шигырьне хә- тер диктанты итеп язарга әзерләнеп килергә | 13.03. | | |
| 26 | 1 | Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр. | Җөмләдә тиндәш кисәкләрнең я алдында, яки соңында аларны тулысынча алыштыра торган сүзләрнең гомумиләштерүче сүзләр дип аталуы. Тиндәш кисәкләр алдыннан килгән | | 238нче күнегү, бирем буенча | 20.03. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | гомумиләштерүче сүздән соң ике нокта куелу, тиңдәш кисәклардән соң килгән гомумиләштерүче сүз алдыннан сызык куелу. | | | | | |
| | | ҖӨМЛӘДӘ СҮЗ ТӘРТИБЕ | | | | | | |
| 27 | 1 | Сүзләрнең уңай һәм кире тәртибе<br>Логик басым | Татар телендәге сүз тәртибенең рус телендәге сүз тәртибеннән аерылуы. Иянең хәбәрдән алда килүе, ә хәбәрнең җөмләне тәмамлап куюы. Җөмләдә сүзләрнең уңай һәм кире (инверсия) тәртибе<br>Җөмләдә мәгънәсе ягыннаниң әһәмиятле сүзнең логик басым төшкән булуы. Логик басым төшкән сүзнең тыңлаучы өчен күпмедер дәрәҗәдә яңалык бирүе. Гадәттә логик басымның хәбәргә төшүе. Башка кисәккә төшкәндә, ул кисәкнең хәбәр алдыннан куелуы. | | Шигырьне хәтер диктанты итеп язарга әзерләнеп килергә | 03.04. | | |
| | | ГАДИ ҖӨМЛӘ | | | | | | |
| 28 | 1 | Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре. Хикәя җөмлә. Сорау җөмлә.<br>Боеру җөмлә. Тойгылы җөмлә | Сөйләүченең нинди максат белән әйтүеннән чыгып, җөмләнең төрләре: хикәя җөмлә, сорау җөмлә, боеру җөмлә, тойгылы җөмлә. Берәр эш яки хәл турында хәбәр итә торган җөмләрең хикәя җөмлә дип аталуы. Аның тыныч тавыш белән | Гариза язу. | Әдәби әсәрләрдән җөмләләр язып килергә | 10.04. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | әйтелүе. Сорауны эченә алган һәм сорау интонациясе белән әйтелә трган җөмләнед сорау җөмләдип аталуы. Сорау җөмләләрнең сорауны белдерә торган сүзләр (сорау алмашлыклары) белән, сорау кисәкчәләре ярдәмендә, яки бары тик сорау интонациясе беоән генә белдерелүе.<br>Сөйләүченең берәр эшне кушарга яки аннан тыелырга кушуын белдергән җөмләнең боеру җөмлә дип аталуы.<br>Көчле хис белән әйтелгән җөмләнең тойгылы җөмлә булуы. | | | | | |
| | | И К Е С О С Т А В Л Ы Җ Ө М Л Ә Л Ә Р | | | | | | |
| 29 | 1 | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр | Иясе һәм хәбәре булган яки алар сүз сөрешеннән беленә торган җөмләнең ике составлы җөмлә булуы. Баш кисәкләрнең берсе генә булып, икенчесе сүз сөрешеннән дә беленмәсә, андый җөмләнең бер составлы җөмлә булуы.<br>Баш кисәкләрдән генә торган җөмләнең җыйнак җөмлә дип, баш кисәкләрдән башка иярчен кисәкләре дә булган | | 288нче күнегү, бирем буенча | 17.04. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | җөмләнең җәенке җөмлә дип аталуы. | | | | | |
| | | Б Е Р С О С Т А В Л Ы Җ Ө М Л Ә Л Ә Р | | | | | | |
| | | Бер составлы җөмләләр. Исем җөмлә Фигыль җөмлә Сүз җөмлә | Бер генә баш кисәге булган (икенчесен өстәп булмый торган) җөмләнең бер составлы җөмлә дип аталуы. Бер составлы җөмләләрнең исем җөмлә, фигыль җөмлә, сүз җөмләләргә бүленүе. Баш кисәкләрдән тик иясе генә булган җөмләнең исем җөмлә дип аталуы. Исем җөмләнең предметның булуын атап әйтүе, ә аның эше яки хәрәкәте турында берни дә белдермәве. Иясе булмаган җөмләнең (аны сүз сөрешеннән дә табып булмый) фигыль җөмлә дип аталуы. | | Шигырьне хәтер диктанты итеп язарга әзерләнеп килергә | 24.04. | | |
| | | Т У Л Ы һ Ә М К И М Җ Ө М Л Ә Л Ә Р | | | | | | |
| 30 | 1 | Тулы һәм ким җөмләләр турында төшенчә. Раслау һәм инкарь җөмләләр | Җөмләдә кирәкле кисәкләрнең барысы да булу-булмавыннан чыгып, җөмләләрнең тулы һәм ким җөмләләргә бүленүе. Мәгънә ачыклыгы өчен кирәкле барлык кисәкләре дә булган җөмләнең тулы җөмлә дип аталуы. Алдагы җөмләләрдән яки сүз сөрешеннән җиңел аңлашыла торган бер яки | | Тулы һәм ким, раслау һәм инкарь җөмләләр кулланып “Яз сулышы” дигән хикәя язып килергә. | 08.05. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | берничә кисәге төшереп калдырылган җөмләнең ким җөмлә дип аталуы. Чынбарлыктагы күренешләрне раслау яки инкарь итүгә бәйле рәвештә җөмләләрнең раслау һәм инкарь җөмләләргә бүленүе. | | | | | |
| | | ТУРЫ ҺӘМ КЫЕК СӨЙЛӘМ | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 31 | 1 | Туры һәм кыек сөйләм турында төшенчә Диалог | Сөйләмне башкаручының сөйләүче яки автор дип аталуы. Сөйләүченең үз сүзләре-автор сөйләме, ә сөйләүче кулланган башка кеше сүзләренең чит сөйләм дип аталуы. Үзгәртелмичә кулланылган чит сөйләмнең туры сөйләм дип, ә үзгәртелеп кулланылган чит сөйләмнең кыек сөйләм дип аталуы. Туры сөйләмнең төрләре: диалог, монолог, цитата. Персонажларның үз-үзенә, башка берәүгә яисә халыкка мөрәҗәгать ителгән сөйләме монолог дип аталуы. Ике яки берничә кешенең үзара сөйләшүен диалог дип атау. Аерым кешенең диалог эчендәге сүзләрен реплика дип атау. Язма әсәрләрдән алынган туры сөйләмнең цитата дип аталуы. | | 320 нчы күнегү, бирем буенча. 325 нчы күнегү, бирем буенча. | 15.05. . | | |
| 32 | 1 | Туры сөйләм янында тыныш билгеләре | Туры сөйләмнең куштырнаклар эченә алынуы. Туры сөйләм янында тыныш билгеләре куюның өч төргә бүленүе. | | 333 нчы күнегү, бирем буенча 334 нчы күнегү, бирем | 22.05. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | буенча | | | |
| | | ЕЛ БУЕНА ҮТКӘН НӘРНЕ КАБАТЛАУ | | | | | | |
| 33 | 1 | Контроль диктант | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү | Диктант №7 “Яз җитте ” | | 29.05. | | З.Н. Хәбибуллина, М.А. Вәлиуллин, Х.Г. Фәрдиева. V-XI сыйныфлар өчен язма эшләр, Казан, 2003, 81 нче бит |

# Укытуны материаль-техник һәм мәгълүмати  яктан тәэмин итү

Татар теленә өйрәткәндә, түбәндәге материаль-техник чаралардан файдалану таләп ителә:

- күрсәтмә әсбаплар;
- белешмә материаллар;
- аудио һәм видео әсбаплар;
- компьютер программалары;
- электрон китапханә;
- татар сайтлары (belem.ru; tatarile.org.com);

Укыту – методик комплекты


1. 8 нчы сыйныфта татар теле дәреслеге. (Р.Ә. Асылгәрәева, Р.А. Юсупов, М.К. Зиннуров. .  Казан, “Мәгариф” )
2. Татар теле морфологиясе. Ф.М. Хисамова.- Казан, “Мәгариф”, 2005.
3. Хәзерге татар әдәби теле Ф.С.Сафиуллина, М.З.Зәкиев. – Казан, “Мәгариф”, 1994.
4. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. Ф.С.Вәлиева, Г.Ф.Саттаров.-Казан:”Раннур”, 2000.
5. Татар теленнән күнегүләр һәм тестлар. Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова. Казан, “Яңалиф”, 2006.
6. Татар теленнән тестлар. Н.В.Максимов. Казан, “Мәгариф”, 2002, 2008.
7. Изложениеләр җыентыгы. Казан, “Мәгариф”, 2003.
8. V-XI сыйныфлар өчен язма эшләр. З.Н.Хәбибуллина, М.А. Вәлиуллин, Х.Г.Фәрдиева. Казан, “Мәгариф”, 2003.